Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

« 24 » июнь 2016 ел № 2

**Арча шәһәр Советының 29.11.2012 № 58 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәр Советының 07.07.2009 №426 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, шәһәр җирлеге халкын муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында Арча шәһәр Советы карар бирә:

1.Арча шәһәр Советының 2016 елның 29 августына Арча шәһәре Советының 29.11.2012 № 58 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2.Арча шәһәр Советының 29.11.2012 ел, №58 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 25.08.2016 елда 16 сәгатьтә ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 нче йорт адресы буенча үткәрергә.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә

тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча гражданнар тәкъдимнәре, кисәтүләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар язмача 25.08.2016 ел 16 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча: ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт, тел.8(84366) 3-12-35 җибәрелә дип билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советының әлеге карарын һәм карар проектын Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И. Г.Нуриев.